Республика Татарстан
Кукморский Муниципальный район
СОВЕТ НЫРТИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

Татарстан Республикасы
Кукмара муниципаль районы
НЫРТЫ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

422136, Республика Татарстан, Кукморский район,
п. Ныртинского совхоза, ул. Школьная, д.7
тел.: 8(84364) 39-2-52
эл. почта: Nirt.Kuk@tatar.ru

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының
Нырты авыл җирлеге Советы

# КАРАР

16 июнь 2025 ел № 15

Нырты авыл җирлеге Советының 2018 елның 21 июнендәге 12 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Нырты авыл җирлегенең вәкаләтләрне даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль хезмәт турында 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Кодексы, «Татарстан Республикасында үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларга, җирле үзидарәнең сайлап куелган вазыйфаи затларына, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренә, рәис урынбасарларына, аудиторларга, муниципаль хезмәткәрләргә хезмәт хакы түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 14 апрелендәге 228 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә Нырты авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Нырты авыл җирлеге Советының 2018 елның 21 июнендәге 12 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Нырты авыл җирлегенең вәкаләтләрне даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә (алга таба – Нигезләмә), Нырты авыл җирлеге Советының 2018 елның 12 ноябрендәге 25 номерлы, 2020 елның 20 декабрендәге 14 номерлы, 2022 елның 29 декабрендәге 38 номерлы, 2024 елның 11 июнендәге 16 номерлы, 2024 елның 13 августындагы 22 номерлы, 2024 елның 14 августындагы 22 номерлы, 2024 елның 05 декабрендәге 33 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып, түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 2.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.1. Муниципаль берәмлек башлыгына айлык акчалата түләү түбәндәгедән артмаган күләмнәрдә билгеләнә:

| Вазыйфаның исеме | Айлык акчалата түләүнең күләме (сумнарда) |
|---|---|
| | Уникенче төркем (халык саны 1,5 мең кешегә кадәр) |
| Муниципаль берәмлек башлыгы | 21 091,0 |

б) 2.4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.4. Айлык акчалата түләү 12 төркемгә кертелгән муниципаль берәмлек башлыгы өчен нормативтан артмаган күләмдә түләнә – елына 15,48 айлык акчалата түләү.»;

в) 3.1 пунктның беренче абзацында «13990» санын «15389» санына алмаштырырга.

г) 3.5 пунктында «41 процент» сүзләрен «58 процент» сүзләренә алмаштырырга;

д) 4 бүлекнең 1 пунктындагы 6 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6) айлык акчалата түләү – хезмәт окладына карата 58 проценттан артмаган күләмдә.»

2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2025 елның 1 маеннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Нырты авыл җирлеге башлыгы Т.А. Кутдусов